**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күлле-Киме авыл җирлеге Бактачы торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"24" ноябрь 2025 ел. № 2

2025 елның 20 мартындагы « Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ номерлы Федераль законының 45, 69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №109 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең Бактачы торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Бактачы авылы территориясендә 2026 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең Бактачы авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 6000 (алты мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (урамнарны кардан чистарту, Бактачы авылына юлны ремонтлау, вак таш сатып алу һәм салу, эш һәм хезмәт күрсәтү өчен түләү)

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең Бактачы авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күлле-Киме авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Бактачы авылында узган халык җыены карарын "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы Гиниятов И.С.

Совет Кулле-Киминского сельского поселения
Күлле-Киме авыл җирлеге советы